**СОВЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ**
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**
**28 февраль, 2023 ел** **№ 276**

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының муниципаль вазыйфаларны биләүче затларны, җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләрен һәм бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү буенча Бердәм тариф челтәре таралмый торган бюджет өлкәсенең аерым оешмалары хезмәткәрләрен премияләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 гыйнварындагы 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Биектау муниципаль районы Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының муниципаль вазыйфаларны биләүче затларны, җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләрен һәм бюджет өлкәсендә хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү буенча Бердәм тариф челтәре таралмый торган бюджет өлкәсенең аерым оешмалары хезмәткәрләрен премияләү турында нигезләмәне кушымта нигезендә расларга.

2. Биектау муниципаль районының җирле үзидарә органнары җитәкчеләренә әлеге карарга таянып эш итәргә.

3. Әлеге карарны Биектау муниципаль районының рәсми сайтында: http//vysokaya-gora.tatarstan.ru һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда: http://pravo. tatarstan.ru веб-адрес буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

4. Әлеге карар 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советының бюджет, финанс һәм икътисадый сәясәт буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Совет рәисе,
муниципаль район башлыгы Р.Ф. Хисамутдинов

1 нче кушымта

«Расланды»
Татарстан Республикасы
Биектау муниципаль районы
Советының 2023 елның «28»
февралендәге 276 номерлы
карары белән

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының муниципаль вазыйфаларны биләүче затларны, җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләрен һәм бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү буенча Бердәм тариф челтәре таралмый торган бюджет өлкәсенең аерым оешмалары хезмәткәрләрен премияләү турында**
# НИГЕЗЛӘМӘ

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмә муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар, җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләре һәм бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү буенча Бердәм тариф челтәре таралмый торган бюджет өлкәсенең аерым оешмалары хезмәткәрләре эшчәнлеге нәтиҗәлелеген, аларга бюджет даирәсе хезмәткәрләренә йөкләнгән вәкаләтләрне үтәү, башкарыла торган бурычларның сыйфатын арттыру арттыру, вазыйфаи инструкциядә каралган вазыйфаи бурычларны вакытында һәм намус белән үтәү максатларында, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының муниципаль вазыйфаларын биләүче затларга һәм җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләренә премияләр түләү тәртибен һәм шартларын билгели, муниципаль вазыйфаларны биләүче затларга, җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләренә һәм бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү буенча Бердәм тариф челтәре таралмый торган бюджет өлкәсенең аерым оешмалары хезмәткәрләренә түбәндәге төр премияләр түләнә:

-аеруча мөһим һәм катлаулы бурычларны үтәгән өчен премия;

- ай саен бирелә торган премия;

- квартал саен бирелә торган премия;

- календарь, милли бәйрәм чараларына багышланган премия;

- аеруча мөһим һәм катлаулы биремнәрне үтәгән өчен бер тапкыр бирелә торган премия;

- ел буена эш нәтиҗәләре буенча еллык премия.

1.2. Муниципаль вазыйфаларны биләүче затларга әлеге нигезләмә максатлары өчен түбәндәгеләр керә:

- Биектау муниципаль районы башлыгы;

- Биектау муниципаль районы башлыгының даими нигездә урынбасары;

- Биектау муниципаль районының Контроль-хисап палатасы рәисе.

1.3. Премияләр түләүгә чыгымнарны финанслау, хезмәткә түләү фонды һәм агымдагы финанс сметасы экономиясе булганда, финанс елына бюджет турында

расланганнан тыш бюджетны үтәгәндә фактта алынган табышлар һәм агымдагы финанс елы башына барлыкка килгән район бюджеты хисабындагы акчаларның калган өлешләре булганда, оптимизация чаралары үткәрүдән җирле бюджет акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла.

1.4. Премияне түләү һәм мәхрүм итү түбәндәгеләр тарафыннан рәсмиләштерелә:

1.4.1 Муниципаль вазыйфаларны биләүче затларга, Башкарма комитет җитәкчесенә - Биектау муниципаль районы башлыгы боерыгы белән.

1.4.2. Финанс-бюджет палатасы, Биектау муниципаль районының Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисләренә - Биектау муниципаль районы башлыгы боерыгы белән.

1.4.3. бюджет даирәсендә эшләүчеләрнең хезмәтенә түләү буенча муниципаль хезмәткәрләргә һәм Бердәм тариф челтәре таралмый торган бюджет өлкәсендәге аерым оешмаларның хезмәткәрләренә - җирле үзидарә органы җитәкчесе күрсәтмәсе белән.

1.5. Премиянең күләме түбәндәгечә билгеләнә:

- аеруча мөһим һәм катлаулы биремнәрне үтәгән өчен премия өчен вазыйфаи окладтан процент нисбәтендә;

- квартал саен бирелә торган премияләр, календарь, милли бәйрәм чараларына һәм аеруча мөһим һәм катлаулы биремнәрне үтәү өчен бер тапкыр бирелә торган премияләр өчен ике айлык акчалата хезмәт хакыннан артык булмаган күләмдә;

- юбилей даталарына җирле үзидарә органнары хезмәткәрләренең бер айлык акчалата хезмәт хакыннан артык булмаган күләмдә;

1.6. Муниципаль район башлыгы, Муниципаль район башлыгы урынбасары, Муниципаль район башкарма комитеты җитәкчесе күрсәтелгән премияләрдән тыш, республика һәм федераль хакимият органнары күрсәтмәләре нигезендә премияләр алырга мөмкин.

1.7. Календарь ел өчен әлеге Нигезләмәнең 3-5 бүлекләрендә каралган премияләрнең гомуми күләме муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар, җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләре һәм бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү буенча Бердәм тариф челтәре таралмый торган бюджет өлкәсенең аерым оешмалары хезмәткәрләренең унике айлык акчалата хезмәт хакыннан артып китә алмый.

1.8. Әлеге Нигезләмәнең 3 һәм 5 бүлекләрендә билгеләнгән премияләр индивидуаль рәвештә аерым муниципаль хезмәткәрләргә, муниципаль вазыйфаны биләүче затларга һәм бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү буенча Бердәм тариф челтәре таралмый торган бюджет өлкәсендәге аерым оешмаларның хезмәткәрләренә түләнергә мөмкин.

1.9. Премияләү мәсьәләләре буенча индивидуаль хезмәт бәхәсләре хезмәт законнарында билгеләнгән тәртиптә хәл ителә.

## 2. Аеруча мөһим һәм катлаулы биремнәрне үтәгән өчен премияләр

2.1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренә, муниципаль вазыйфаларны биләүче затларга, җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләренә һәм бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең

хезмәтенә түләү буенча Бердәм тариф челтәре таралмый торган бюджет өлкәсенең аерым оешмалары хезмәткәрләренә эш нәтиҗәләре буенча асылда эшләнгән вакыт өчен вазыйфаи окладның проценты күләмендә аеруча мөһим һәм катлаулы биремнәрне үтәгән өчен ай саен премия түләнә

| вазыйфа | Түләү күләме, вазыйфаи окладтан %ларда |
|---|---|
| Совет аппараты җитәкчесе | 25 |
| Палата рәисе | 60 |
| Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары | 60 |
| Эшләр идарәчесе | 60 |
| Башлык ярдәмчесе (коррупциягә каршы көрәш мәсьәләләре буенча) | 60 |
| Бүлек башлыгы | 55 |
| Мөстәкыйль бүлек башлыгы (мөдире), Башкарма комитетның башка структур бүлекчәсе (аппараты) җитәкчесе | 55 |
| Сектор мөдире | 50 |
| Бүлек башлыгы урынбасары | 30 |
| Баш белгеч | 30 |
| Әйдәп баручы белгеч | 30 |
| Административ комиссиянең баш белгеч-җаваплы секретаре | 75 |
| Баш белгеч (тәрҗемәче) | 75 |
| Алып баручы белгеч (ВТП) | 75 |
| Автомобиль йөртүчесе | 130 |
| «Теплосервис» МБУ директоры, «АТИ» МКУ башлыгы | 100 |

2.2. Аеруча мөһим һәм катлаулы биремнәрне үтәгән өчен премия түбәндәге очракларда түләнми:

- 3 һәм аннан да күбрәк документларны (мөрәҗәгатьләрне, хатларны) карау срокларын бозганда;
- Район башлыгының, җирле үзидарә органы җитәкчесенең ай дәвамында 1 һәм аннан да күбрәк беркетмә йөкләмәләрен үтәмәү яисә тиешенчә үтәмәү;
- мөлкәтне юкка чыгаруга китермәгән муниципаль мөлкәткә матди зыян салу;
- шелтә рәвешендә дисциплинар җәза булу;
- вазыйфаи бурычларын үтәгәндә өченче затка мәгълүм булган хезмәт мәгълүматын тарату;
- муниципаль хезмәт узуга, хезмәт тәртибе йөкләмәләренә һәм кагыйдәләренә, мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яисә җайга салу турындагы таләпләргә бәйле чикләүләрне һәм тыюларны үтәмәү, коррупциягә каршы көрәш максатларында билгеләнгән бурычларны үтәмәү.

### 3. Квартал саен түләнә торган премия

3.1 Муниципаль вазыйфаларны биләүче затларга, җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләренә һәм бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү буенча Бердәм тариф челтәре таралмый торган бюджет өлкәсенең аерым оешмалары

хезмәткәрләренә эш бирүче карары буенча квартал саен бирелә торган премияләр түләнергә мөмкин.

3.2. Тулы булмаган ай дәвамында эшләгән муниципаль вазыйфаларны биләүче затларга, җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләренә һәм бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү буенча Бердәм тариф челтәре таралмый торган бюджет өлкәсенең аерым оешмалары хезмәткәрләренә эш нәтиҗәләре буенча премия асылда эшләнгән вакыт өчен түләнә.

3.3. Квартал саен бирелә торган премияләр түбәндәге очракларда киметелергә мөмкин:

- гражданнарны карау, шул исәптән башка учреждениеләрдән, оешмалардан кергән мөрәҗәгатьләр буенча срокларын үтәмәгәндә, хезмәт документлары белән эшләү тәртибен бозганда - 50 %ка кадәр;

- кисәтү рәвешендә дисциплинар җәзалар булган өчен - 50% ка кадәр, шелтә булганда - 100% ка кадәр;

- Район башлыгының, җирле үзидарә органы җитәкчесенең беркетмә күрсәтмәсен үтәмәгән яисә тиешенчә үтәмәгән өчен - 50 %ка кадәр;

- хезмәтне саклау һәм техника иминлеге, янгын куркынычсызлыгы таләпләрен үтәмәгән өчен - 20%ка кадәр;

- озак сроклы муниципаль программалар башкаручыларга һәм региональ һәм федераль программаларны гамәлгә ашыру өчен җаваплы, программаны яисә аның аерым чараларын вакытында һәм сыйфатсыз гамәлгә ашырган, программаны гамәлгә ашыруга юнәлтелгән район бюджеты акчаларын нәтиҗәле һәм максатчан файдалануны тәэмин итмәгән өчен - 50 %ка кадәр.

3.4. Квартал саен бирелә торган премиянең күләме ике айлык акчалата хезмәт хакыннан артып китә алмый.

3.5. Квартал саен бирелә торган премияләр эш бирүче карары буенча, шулай ук хезмәт бурычларын үтәмәү яисә тиешенчә үтәмәү сәбәпле, шелтә рәвешендә дисциплинар җәзалар булган очракта түләнми.

3.6. Квартал премиясе муниципаль вазыйфаларны биләүче затларга, җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләренә һәм бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү буенча Бердәм тариф челтәре таралмый торган бюджет өлкәсенең аерым оешмалары хезмәткәрләренә түләү вакытына:

- баланы карау ялында;

- акчалата түләү сакламыйча гына отпускта булганда түләнми.

**4. Календарь, милли бәйрәм чараларына**
**багышланган премия**

4.1. Календарь, милли бәйрәм чараларына багышланган премия бер мәртәбә акчалата бүләкләү булып тора.

4.2. Календарь, милли бәйрәм чараларына багышланган премия җирле үзидарә органында эшләүче муниципаль вазыйфаларны биләүче барлык затларга, муниципаль хезмәткәрләргә һәм бюджет даирәсендә эшләүче хезмәткәрләргә хезмәт өчен түләү буенча Бердәм тариф челтәре кагылмый бюджет өлкәсендәге аерым оешмаларның хезмәткәрләренә календарь яисә милли бәйрәм чарасы датасына түләнә.

4.3. Календарь, милли, бәйрәм чараларына багышланган премия ике айлык

акчалата хезмәт хакыннан артык була алмый.

## 5. Ел нәтиҗәләре буенча еллык премия

5.1. Муниципаль вазыйфаларны биләүче затларга, җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләренә һәм бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү буенча Бердәм тариф челтәре таралмый торган бюджет өлкәсенең аерым оешмалары хезмәткәрләренә бер ел эшләү нәтиҗәләре буенча еллык премия гамәлгә ашырылырга мөмкин.

5.2. Ел нәтиҗәләре буенча премия күләме хезмәткә түләү фондының экономияләү күләменә карап билгеләнә.

5.3. Тулы булмаган ел дәвамында эшләгән муниципаль вазыйфаларны биләүче затларга, җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләренә һәм бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү буенча Бердәм тариф челтәре таралмый торган бюджет өлкәсенең аерым оешмалары хезмәткәрләренә премия асылда эшләнгән вакыт өчен түләнә.

5.4. Еллык премияләр, шелтә рәвешендә дисциплинар җәза булган очракта, вазыйфаи бурычларны үтәмәгәндә яисә тиешенчә үтәмәгәндә тулысынча түләнми.

5.5. Еллык премия муниципаль вазыйфаларны биләүче затларга, җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләренә һәм бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү буенча Бердәм тариф челтәре таралмый торган бюджет өлкәсенең аерым оешмалары хезмәткәрләренә түләү вакытына:

- баланы карау ялында;
- акчалата түләү сакламыйча гына отпускта булганда түләнми.

## 6. Татарстан Республикасы муниципаль хезмәткәрләре Спартакиадасында катнашучыларга премия

6.1. Муниципаль хезмәткәрләр һәм муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар Спартакиадасында катнашучыларны стимуллаштыру максатларында актив һәм нәтиҗәле катнашкан өчен акчалата премия күләмнәрен билгеләргә

- аерым спорт төре, команданың һәр катнашучысы өчен:

1 нче урын 10 000 сум
2 нче урын 7 000 сум
3 нче урын 5 000 сум

- бөтен Спартакиада нәтиҗәләре буенча гомумкоманда урыны өчен, спартакиаданың барлык катнашучыларына:

1 нче урын 15 000 сум
2 нче урын 10 000 сум
3 нче урын 5 000 сум.